КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2018 ел, 19 ноябрь | г.Казань | № 1012

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спорт чараларын, теннисны пропагандалау, популярлаштыру һәм алга таба үстерү чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 4 июль, 547 нче карары белән расланган Спорт чараларын, теннисны пропагандалау, популярлаштыру һәм алга таба үстерү чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спорт чараларын, теннисны пропагандалау, популярлаштыру һәм алга таба үстерү чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 4 июль, 547 нче карары белән расланган Спорт чараларын, теннисны пропагандалау, популярлаштыру һәм алга таба үстерү чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«С = З_{fot} + З_{n} + З_{k} + З_{u} + З_{r} + З_{ar} + З_{of} + З_{kt} + З_{ob} + З_{rek} + З_{s} + З_{cer} + З_{pr} + З_{med} + З_{st} + З_{bez} + \\ + З_{sv} + З_{ak} + З_{gsm} + З_{vod} + З_{ser} + З_{vs} + З_{kur} + З_{mer} + З_{bil} + З_{ar} + З_{tm.}»;$$

егерме тугызынчы һәм утызынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$З_{ar}$ – җир кишәрлекләрен, спорт корылмаларын, спорт объектларын арендалау, чаралар үткәрү өчен техник чаралар һәм ярдәмче җиһаз сатып алу, шулай ук аларны кору, сүтү, эшләтеп җибәрү һәм аларга хезмәт күрсәтү чыгымнары;

$З_{tm}$ – Татарстан Республикасы җыелма командасының теннис буенча күнегүләр чараларын, теннис буенча турнирлар оештыру һәм үткәрү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү чыгымнары;»;

түбәндәге эчтәлекле утыз беренче абзац өстәргә:

«Бу пунктта күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар Министрлык тарафыннан бер төрле товарларның, эшләр башкаруның, хезмәтләр күрсәтүнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән оештыручы-җитештерүчеләр бәяләре турында, дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта («Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге җитештерүчеләр һәм тәэмин итүчеләрнең рәсми сайтларын кертеп) булган бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт булган чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин